«Килешенгән»
Яр Чаллы шәһәре Башкарма
комитеты житәкчесе
Сәлахов Фәрит Шәфкат улы

«Раслыйм»
ТР МДН мөфтие
Камил хәзрәт Сәмигуллин

# НИГЕЗЛӘМӘ

## Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте кубогына мөселманнарның татар милли көрәше һәм кул көрәше буенча берләштерелгән каһарманар елына багышланган XVI Россиякүләм турниры

### 1. Максат һәм бурычлар:

- татар халкының милли спорт төрләрен һәм традицияләрен актив тормыш рәвешенә кертү;
- мөселманнар арасында татар милли көрәшен һәм кул көрәшен киң җәелдерү һәм үзара дуслык, туган илгә карата патриотизм җепләрен тагын да ныгыту;
- мөселманнарда сәламәт яшәү, чыдамлык, түземлек сыйфатларын тәрбияләү өчен шартлар тудыру.

### 2. Бәйгене үткәрү вакыты һәм урыны:

- бәйге Чаллы шәһәренең «Витязь» спорткомплексында 2025 елның 15 ноябрь көнендә уздырыла (адресы: Яр Чаллы проспекты, 23 йорт, «Челныгорстрой» тукталышы. Телефоны: 8(8552) 56-65-99).

Шәхси-команда ярышлары олимпия системасы буенча үткәрелә:

- иртәнге сәгать 8 дән 9 га кадәр – катнашучыларны үлчәү, намаз кагыйдаләре буенча тест;
- сәгать 9 дан 9.30 га кадәр – вәкилләр һәм хөкемдарлар җыелышы;
- сәгать 10.00 да – бәйгене ачу.

### 3. Бәйгенең җитәкчелеге:

- бәйгеләрне әзерләүче һәм уздыручы гомумҗитәкчелек – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте, Чаллы шәһәре башкарма комитеты, Россия көрәш Федерациясе, Татарстан Республикасы көрәш Федерациясе һәм Чаллы шәһәре мөхтәсибәте.
- төп иганәчеләр: Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте, ООО ГК "Профит" генераль директоры Мингалимов Марсель Җәвит улы.
- төп хөкемдар – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәтенең баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев.

- турыдан-туры җитәкчелек вазыйфасы Чаллы мөхтәсибәте һәм хөкемдарлар коллегиясенә йөкләнелә.

### 4. Бәйгедә катнашучылар һәм бәйгеләрне уздыру шартлары:

- бәйгеләрдә 18 яшьтән кече булмаган, ***намаз укучы***, тиешле физик әзерлеккә һәм медицина рөхсәтенә ия мөселманнар гына катнаша ала;
- көрәш буенча авырлык категорияләре: 65; 75; 85; 95; 105 һәм 105 килограммнан артык;
- кул көрәше буенча авырлык категорияләре: 70 килограммга кадәр, 85; 85 килограммнан артык; ветераннар категориясе - 60 яшь һәм өлкәнрәкләр.
- үлчәнгәнгә кадәр, ***катнашучылар намаз уку кагыйдәләрен белү буенча тест үтәргә тиеш;***
- бәйгедә катнашучыларның үзләре белән паспорт, ИНН, СНИЛС булырга тиеш;
- ***бәйгеләр җирәбә тәртибе буенча уздырыла;***
- бәйгедә катнашучылар барысы да көрәшкә кагылышлы спорт киеменнән һәм түбәтәйдән булырга тиеш.

### 5. Бүләкләү:

- һәр авырлык категориясе җиңүчеләренә диплом һәм кыйммәтле бүләк тапшырыла;
- җиңүче командага Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте Кубогы бирелә;
- ***үз авырлык категориясендә беренче урын яулаганнар арасында җирәбә салына, отучыга турнирның төп бүләге –Хаҗга юллама тапшырыла.***

### 6. Финанс чыгымнары:

- турнирны әзерләү һәм уздыру, җиңүчеләрне бүләкләү өчен тотылган бар чыгымнарны бәйгене оештыручылар хәл итә;
- бәйгедә катнашучы спортчыларның, хөкемдарларның, тренерларның чыгымнарын (юл хакы, туклану, яшәү урыны) аларны командировкага юллаучы оешмалар түли.

### 7. Гаризалар:

- командировкага җибәрүче оешма һәм табиб тарафыннан расланган гаризалар 2025 елның 15 ноябрь көненә кадәр хөкемдарлар коллегиясенә тапшырыла;
- бәйгедә катнашучы һәркемнең бәхетсезлек очракларыннан страховка кәгазе булырга тиеш;
- үлчәнер алдыннан һәр катнашучы үзенең паспортын күрсәтергә тиеш.